РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Простинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423553, Нижнекамский район,
с. Прости, ул. Школьная, 8

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Прости авыл җирлеге
Башкарма комитеты

423553, Түбән Кама районы,
Прости авылы, Мәктәп урамы, 8

тел./факс (8555) 44-98-35, электронный адрес: Prostinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.prostinskoe-sp.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.02.2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 3 февралендәге 3 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» карарын игътибарга алып, карар бирәм:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге башкарма комитеты карарлары:

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр реестры турында» 2011 елның 18 май аендагы 9 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 декабрендәге 28 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлегенең муниципаль милкен арендага бирү буенча муниципаль хезмәт

күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 декабрендәге 31 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан социаль наем шартнамәсе буенча торак бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 декабрендәге 33 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документларының күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 декабрендәге 34 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлегенең муниципаль милкен арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 декабрендәге 23 номерлы карары;

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Прости авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Исполнительный комитет Простинского сельского поселения

Д.А. Бәдәртинов